ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

№ 16 11.02.2021

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында»
2020 ел, 2 март, 115 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 ел, 31 июль, 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советының Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында 2020 ел, 2 март, 115 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

15 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмыйлар»;

20 статьяның 3 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;20 статьяның 3 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

34 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге мәгълүматларны мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль

(персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру».

2. Карарны Мюд авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aksubaevo.tatar.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе: Т.В. Зюзина